| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**15.05.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1324** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3924 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3924 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 19 мартындагы 715 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.14.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«берничә мөрәҗәгать итүченең берничә мөрәҗәгать итүче белән уртак рәсми мөрәҗәгатьне җибәрүне күз алдында тоткан хезмәт күрсәтүләрне сорап мөрәҗәгать иткәндә рәсми мөрәҗәгатьнең бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге»;

1.2. 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16) пунктча өстәргә:пункт:

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү «Физик затларны биометрик шәхси мәгълүматлардан файдаланып идентификацияләү һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз

көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган Россия Федерациясе гражданы паспортын яисә шәхесне таныклый торган башка документны күрсәтү юлы белән яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, мәгълүмати технологияләр кулланып күпфункцияле үзәкләрдә идентификация һәм аутентификация юлы белән шәхси кабул итү барышында гамәлгә ашырылырга мөмкин. »

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин